**ГЛАВА**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2023 Исәнбай авылы № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2023 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Исәнбай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2023 елның 16 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Исәнбай авылы Совет ур., Хезмәт ур., Речная ур., Ленин ур. халкы

-2 этап: Исәнбай авылы Мәктәп ур., Береговая ур., Яшьләр ур., Кирпич ур., Октябрь ур. халкы

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Исәнбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан

тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

**1. Урам яктырту челтәрләрен ремонтлау:**

1.1 урам яктырту өчен энергия саклаучы фонарьлар, лампалар һәм материаллар сатып алу һәм алыштыру.

**2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировканы һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау:**

2.1 сантехник материаллар сатып алу һәм җирлекне су белән тәэмин итү (тирән насослар сатып алу һәм ремонтлау, суүткәргеч челтәрен ремонтлау)

**3. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:**

3.1 Исәнбай авылында рөхсәтсез чүплекләрне бетерү өчен дизель ягулыгы, дизель мае һәм трактор запас өлешләрен тоту, хезмәт күрсәтү һәм сатып алу, чүп үләннәрен чабу.

3.2 Трактор өчен роторлы чапкыч сатып алу.

**4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

4.1 Исәнбай авылында Совет, Октябрь, Яшьләр урамнары буенча юллар салу өчен вак таш сатып алу һәм өлешчә ремонтлау һәм Исәнбай авылында урамнарны кардан чистарту.

**5. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү**:

5.1 Исәнбай авылында Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәре хөрмәтенә истәлек тактасын проектлау һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 79 йорт, авыл мәдәният йорты.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Ф.Ф.Сираев